Минһаҗева, З. «Җиде кат ябылган ишекне сигезенче тапкыр шаку кирәк» / З. Минһаҗева; [әңгәмәдәш] Р. Гасыймова // Мәйдан. – 2025. – №4 (281). – Б. 106-116

***Зөләйха Минһаҗева:***

# *"Җиде кат ябылган ишекне сигезенче тапкыр шаку кирәк"*



Беркөнне Вконтакте» челтәрендә Зөләйха Минһаҗеваның дүрт юллыгы игътибарны җәлеп итте:

*Авырткан җиреңне әйтми тор,*
*Дошманнар ишетә күрмәсен.*
*Сугарга уйласа, тәгаен*
*Кай җиргә сугарга белмәсен...*

Кызык булып китте. Дөрес, миндә дошманнар юк. Зөләйха апада да юк инде алар. Ә менә шигырь бар. Һәм аның мәгънәсе кешеләр арасындагы мөнәсәбәттән күпкә киңрәк кебек. Менә икенчесе:

*Юлны яктырткан да, яндырган да,*
*Көлгә калдырган да шул ук ут.*
*Бергә көләр кешем күп лә минем,*
*Бергә елар кешем генә юк…*

Елау дигәннән... Еларга яратучылардан түгел инде ул Зөләйха апа. Аның белән танышканыбызга өч дистә еллап бардыр. Бергә ерак сәфәрләргә дә йөрергә туры килде – минем Зөләйха апаның күңелсез чагын күргән булмады. Сиңа да күңелсезләнергә ирек бирми әле ул, дөресен әйткәндә – ул булган җирдә җыр, уен-көлке тынып тормый.

Зөләйха ханым гомер буе мәдәният тармагында эшләде. Чаллы мәдәният идарәсенең баш белгече буларак, шәһәркүләм чараларны (каз өмәсе, Нәүрүз бәйрәмнәрен, Сабан туйларын) оештыру – хезмәтенең бер юнәлеше булса, икенчесе – Зөләйха ханым бу чараларның күбесендә алып баручы буларак үзе дә катнашты. Өстәвенә, бик күп Чаллы җырчыларының концерт-тамашаларын да алып барды әле ул. Театр мәктәбендә, институтта укытты... Һәм шул арада җырлар авторы, шагыйрә, язучы буларак та игътибарны җәлеп итәргә өлгерде: аның сүзләренә язылган, даими башкарылган җырларның исәбе-хисабы юктыр, ә шигырь-хикәяләре, пьесалары тупланган китапларының саны инде тугызга җитте. Һәм һаман да эштән туктаганы юк Зөләйха ханымның – соңгы елларда «Эврика» мәдәният үзәгендә режиссер булып эшли. Кызыклы кичәләр оештыралар, үзешчәннәр туплап, спектакльләр куялар, грант яулап, мәдәни тапшырулар алып баралар бу үзәктә.

Озын сүзнең кыскасы шул: менә шушы кызыклы шәхесне мин «Мәйдан» журналы редакциясенә кунакка чакырдым. Аның белән бергә безгә бәйрәм рухы да «килеп керде».

**– Зөләйха апа, әйдә, башта балачак, яшьлек еллары турында сөйләшәбез. Мин бит сезне азмы-күпме беләм, шуңа күрә яшь чактагы Зөләйханы агач башында, ат өстендә, йә матайда итеп күз алдына китерәм. Кайсы дөрес?**

– Чамалыйсың икән – барысы да дөрес. Ат дигәннән... Кечкенәдән ат җене кагылган иде инде миңа. Күршебездә Шәйхи абзыйның аты бар иде – мин гел шуның тирәсендә чуалып үстем. Чулпан исемле иде ул. Табыннан шикәр эләктереп чыгып китәм дә Чулпанны сыйлыйм. Ат утары киртәләп алынган була бит инде. Киртә өстенә менеп басам да көтеп торам – ат, якынрак килеп, мине атландырып китә.

**– Чынлап атта йөри белә идегезмени?**

– Ничек белмәсен инде – бишенче классны тәмамлагач Чулпан белән Сабантуйда ат чабышында да катнаштык әле. Дөрес, беренче килә алмадым, кешедән өркеп, атым тартылып китте дә, егылып калдым. Ә атым барыбер барып җитте.

Аннары матайда... Мотоцикл ук түгел иде ул, мотороллер. Татарча «кәҗә» дип йөртәләр иде бит әле. Ул вакытта авылда әле «сәпид» тә бөтен кешедә булмагандыр. Ә миндә – матай... Җиденче классны бетергәчме инде, әти алып бирде.

Мин үзем Баулы районы Салих авылыннан. Яңа Чүте авылына йөреп укыдык без. Ара якын түгел – җиде чакрымнар булгандыр. Мин бөтен кешенең сумкаларын җыям да «кәҗәм» белән алдан китәм.

Бервакыт кемдер әйтте бит: «Глушителен алып ташласаң, шәбрәк йөри ул», – диде. Алып ташладык. Шуннан соң минем арттан тавыклар гына түгел, әбиләр дә пырлап кала башлады.

Элек мәктәптә тәртиптән билге кую тәртибе бар иде бит. Минем билге гел өчле була торган иде инде. Гел нәрсәдер килеп чыгып тора иде. Йә тәрәзә ватыла инде ялгыш, йә нәрсә.

Мәктәп укучыларын кич белән клубка киногa кертмиләр иде бит – берәр укытучы клуб ишеге төбендә дежурда тора. Ә тегендә шәп кино бара. Индийский! Ике серияле! Әниең белән әтиең шунда утырганда, өйгә кереп ятмыйсың бит инде. Йөрисең урам буйлап этлек эшләп. Югары очта берәр ныграк тормышлы кешенең капкасын Түбән очка хәлсезрәк кешегә күчерәсең. Кызык ясап, эскәмияләрне урамның бер башыннан икенче башына илтеп куясың. Яшьлек дәртенә урын таба алмау булгандыр инде ул. Шуклык.

Бервакыт малайларны линейка каршына чыгарып ачуландылар. Шул ук көнне тегеләр безнең тәрәз каршына килеп болай дип җырладылар:

*Ват, җимер коймасын,*
*Юлга койма кормасын,*
*Мохит абый кызын тыйсын,*
*Безне чыгып тыймасын*!
Әти дә ишетте бит инде моны. Мине җилтерәтеп каршына бастырды да: «Кызый, тагын нәрсә эшләдең?» – ди. Бик коры иде инде әткәй. Мәктәп директоры бит!

**– Ай Аллам, директор кызы да идегезмени әле сез?**

– Әйе. Директор гына түгел, укытучы да – физика, математика укытты. Әнием – географ.

Әле дә хәтеремдә, безнең әни «икеле»гә укучыларны өйгә җыеп алып кайта иде. Үзе өстәлнең бер башында камыр баса. Икенче башына дәреслек белән теге баланы утыртып куя. Шөгыльләнәләр. Шул балалар өчен яшәделәр инде алар икәүләп, дөресен әйткәндә.

Әни әле өстәвенә авылда парторг эшен дә алып барды. Кем ире белән талашкан, кем күршесе белән тыныша алмый – барысы да әни янына килә иде. Ул – дипломат, бөтен кешене җайлый белә.

**– Сез гаиләдә ничә бала инде?**

– Без – өч кыз, ә мин – малай урынына, дияргә яратам инде мин шаяртып. Безнең яшь аермасы бишәр яшь. Зөбәйдә, Зөләйха, Гүзәл – мин уртанчы. Апам белән сеңлем миңа ошамаган – бик итагатьле, тәртиплеләр алар. Аллага шөкер, бик дус, тату без, гел аралашып яшибез.

**– Нигә сез әти-әниегез юлыннан китмәдегез икән, Зөләйха апа?**

– Белмим шул. Алар минем укытучы булуымны телиләр иде, ә мин «юк» дидем. Хезмәт юлымны... фермадан башладым. Җәйге каникулларда болай да ел саен савымчыларны отпускага җибәрә идем. Ә бу юлы алдынгы сыер савучыбыз Галия апа кияүгә китте дә, мин аның төркемен алып калдым. Әни бер дә риза булмады, билгеле.

Бервакыт эштән кайтып керсәм, өйдә район мәдәният идарәсе башлыгы Илдус Сорурович чәй эчеп утыра. Бер-беребезне таныйбыз – мин бөтен смотрларда катнашып, районкүләм концертларда алып баручы булып та йөрим бит ул вакытта. Илдус абый әйтә, бездә Кара Зирек дигән авыл бар, бик матур татар авылы, ди, менә шунда клуб мөдире кирәк, ди. Яңа клуб. Әнием моңа шулкадәр сөенде инде, мин карышып торсам да: «Кеше олы башын кече итеп синең янга килгән, җыен хәзер үк», – дип, шундук төенчекләремне төйнәргә тотынды. Көз иде ул, юллар беткән вакыт, шул китүдән мин өйгә җиде айдан соң гына кайта алдым.

Ә авыл, чыннан да, матур иде. Хәзер дә матур әле ул. Ык буена урнашкан. Гармунчылар шулкадәр күп иде Кара Зиректә – кичке уеннарда гармун кулдан кулга йөри иде.

«Ак калфак» дигән спектакль куйдык бервакыт. Син күрсәң! Сәхнә тулы яшьләр! Төп рольләрне – Бакый белән Хәмдияне яңа гына өйләнешкән пар уйный иде. Әйбәт уйныйлар. Бакыйны үтерделәр бит хәзер. Халык ышанып (ул чакларда кеше бигрәк беркатлы иде инде) яшь түгеп утыра. Хәмдия өзелеп, шундый матур итеп җырлый. Шулай үзе җырлап, үзе елап, янәсе, сәхнәдә «үлеп» яткан Бакыйның өстенә капланды бу. Күрәсең, җайсызрак җиренә баскандыр – үлгән Бакый кинәт кычкырып җибәрмәсенме! Елап утырган халык көләргә тотынды. Трагедияне алга таба ничек дәвам итәсең ди – мин йөгереп чыгып тизрәк пәрдәне яптым. Шуннан безнең бөтен артистлар сәхнәгә чыгып баш иделәр. Ә Бакый белән Хәмдия юк! Халык кычкыра инде: «Бакый, Бакый!» – ди. Аларны эзләп, сәхнә артына чыксам, Бакый белән Хәмдия пыр тузып талашып яталар... Менә сиңа яшь гаиләдә беренче низаг!

Халык ышанучан иде инде, ышанучан... Тагын бер күңелдә калган истәлек. Бервакыт спектакль куйдык. Эчтәлеге болайрак: бер кыз (кыз ролендә мин) егетен армиягә озата, тик көтеп җиткерә алмый, бай егеткә кияүгә чыгып куя. Ә теге (ярлы) егет бик кайгыра инде. Ярлы егет ролендә авыл кибетчесенең малае уйнаган иде. Икенче көнне кердем кибеткә. Сәмия апа мине бик якын итә иде. «Сәмия апа, – мин әйтәм, – шикәр кирәк иде». «Шикәр юк», – ди бу төксе генә. «Алайса, писүк». «Писүк тә юк». «Нишләп алай, Сәмия апа?» – дип кенә бетергән идем, «Минем улым кемнән ким? – дип җавап бирде бу. – Нигә син аны кеше алдында алай рисвай итәсең әле?»

Тискәре рольне уйнаучы юк иде авылда миннән башка. Юньсез кызны да, гайбәтче хатынны да үземә уйнарга туры килә иде гел. Аннары белем җитмәвен сизә башладым мин. Уку елы азагына кадәр эшләдем дә, документларымны алып, Казанга, мәдәният институтына укырга киттем.

**– Ничәнче еллар инде бу?**

– 1971 елда мәдәният хезмәткәре, завклуб булып эшли башладым. Шуннан бирле бүгенге көнгә кадәр мәдәниятта. 54 ел буламы? Бер генә тапкыр да: «Эх, нигә бу эшне сайладым икән», – дип үкенгән чагым булмады минем.

**– Туксанынчы, ике меңенче елларда эшләү кызыграк булгандыр?**

– Әйе. Күпме яңа шәхесләр килеп чыкты бит ул заманда. Җырчы Асия Әхмәтшина, композитор Вәсим Әхмәтшиннар белән бергә эшләргә насыйп булды безгә. Ринат Гобәйдуллин, Илгиз Закировлар... Арттырып әйтмим, ул вакытта татар эстрадасында үзешчәннәр дә, профессоналлар да күпчелек шушы өч композиторның язган җырларын башкаралар иде бит!

**– Институтны тәмамлау белән Чаллыга килдегезме?**

– Юк, мине башта юллама белән Мөслимгә җибәрделәр. Һәм без «Мөслимнәр Чаллыда» дигән зур концерт-тамаша белән Чаллыга килдек. Сюжет өчен Рөстәм Мингалимнең «Чаллы җимерелмәскә салына» дигән поэмасын алдым. Шәп килеп чыкты.

Концерт бетте, без икенче катта ширма артында кием алмашабыз. Ширманың теге ягыннан кемдер эндәшә: «Зөләйха, – ди, – сине сорыйлар монда». Ширма артыннан башымны суздым. Карасам, ике ир-ат басып тора. Аларның берсе – шәһәрнең икенче секретаре булып чыкты, икенчесе – мәдәният бүлеге башлыгы. «Безгә – Чаллыга эшкә килер идеңме?» – диләр. «Килер идем, – дим, – тик мине бит Мөслимгә юллама белән җибәрделәр. Мин анда өч ел эшләргә тиеш». «Это не проблема», – дип җавап бирделәр. Чыннан да проблема булмагандыр – азмы-күпме вакыт узуга, миңа министрлыктан хәбәр килде – төянеп Чаллыга чыгып киттем.

Ул вакытта әле Чаллыда Мансур Кашапович җитәкчелегендәге халык театры эшли иде. Мәскәү сәхнәләрендә чыгыш ясаган саллы театр иде ул. Җитмешәр кеше катнашында «Наемщик»ларны куя алган коллектив. Мине менә шунда режиссер-педагог итеп билгеләделәр. Чаллы кайнап тора. Агитбригадалар белән заводларга йөрибез. Анда әле төзелеш эшләре бетмәгән, бөтен җирдә саз. Безне төзелеш блогы өстенә бастыралар да кран белән өскәрәк күтәртеп куялар. Без шул блоктан ясалган сәхнәдә халыкка концерт бирәбез.

Күпмедер вакыттан, кызганыч, халык театры эшләүдән туктады. Мин тулысынча мәдәният идарәсенә күчтем. Баш белгеч тә булып эшләдем, җитәкче урынбасары да. Ничек кенә атасалар да, барыбер шул ук эшне алып бардым инде. Бервакыт мәдәният идарәсе башлыгы булырга тәкъдим иткәннәр иде – «Җыелышта утыру – минем өчен түгел», – дип баш тарттым. Менә хәзер уйлап карыйм да: табиблар – чир, моң-зар эчендә яши, милиция – тәртипсезлек, җинаять эчендә, ә мин гомерем буе шулкадәр кызык кешеләр арасында кайнап яшәдем. Шуңа әле, җитмәсә, әзрәк түлиләр дә иде бит!

Әзрәк дигәннән... Әз иде инде ул чыннан да. Һаман да шул акча җитмәгәннән «Нократ» ансамблендә алып баручы булып та йөрергә туры килде. Асия һәм Вәсим Әхмәтшиннар белән бергә Уфага россиякүләм фестивальләргә кадәр барып җиттек. Бервакыт шулай мин авырлы,

мине алыштырырдай кеше юк. Вәсим әйтә: «Туктале, – ди, – безнең институтта читтән торып укучылар арасында бер егет бар бит, – ди. – Салават исемле. Нәрсә сөйләгәне бик аңлашылып бетми инде аның. Ну ул булдырачак!»

Салават Фәтхетдинов булып чыкты бу, кыскасы. Ул чыннан да берара безнең ансамбльдә алып баручы булып йөрде. Чаллыда мәдәният идарәсе җитәкчесе булып Илдус Габдрахманович Тарханов эшли иде. Үзе бик әйбәт баянда да уйный белгәнлектәнме, анда тоемлау сәләте шулкадәр көчле. Бервакыт репетиция вакытында Салаватның җырлавына игътибар иткән ул. Һәм, репертуар сайлап, үзен дә җыр белән сәхнәгә чыгарды.

Мин декреттан соң эшкә килгәндә, Салават инде үз концертларын оештыра башлаган иде. Үзем дә күпмедер вакыт Салават концертларында алып баручы булып йөрдем әле. Ул елларда бик күпләр Чаллыда танылып, Казанга күченеп китте. Әмма, беләсеңме, күбесенең «Чаллылыгы» югалмады. Чөнки... Чаллыдагы кебек мохит бер җирдә дә юк ул. Безнең шәһәргә юк-бар кеше килмәгән бит. Гайрәтлеләр, бунтарь йөрәклеләр килгән. Менә шул шаукым әле һаман яши.

**– Зөләйха апа, инде килсәк шигърияткә...**

– Концерт-тамашалар алып баргач, миңа һәрвакыт сәхнәдән сөйләр өчен шигырьләр кирәк була иде инде. Үзем әйтәсе килгән фикерне җиткерә алырдай шигырьләр. Гадәттә мин аларны Кадыйр Сибгатуллин иҗатыннан эзли идем. Анда юк икән, үземә язарга туры килә инде.

Минем бер калын көндәлек дәфтәрем бар иде. Кирәк булган саен шигырь язам да шунда төрткәләп куям. Менә шул дәфтәр бервакыт ниндидер чара вакытында Асия Әхмәтшина кулына килеп эләккән. Ул ачып укыштырган да: «Кара әле, Вәсим, шигырь бит бу!» – дип, ире Вәсимгә (композитор Вәсим Әхмәтшинга) биргән. Вәсим фортепьяно артына утырып аңа шундук көй язган.

*Кайсы мәл булмасын –*
*Көз, яз, җәй һәм кышын,*
*Син мине хәтерлә –*
*Шул сиңа каргышым...*

**– Һәм шулай беренче җырыгыз туды инде?**

– Әйе. Аны инде кемнәр генә башкармады.

Аннары Асия ул дәфтәрне Айдар Хәлимгә укыткан. Бер очрашкач, әйтә Айдар абый: «Зөләйха, китап чыгарырга кирәк», – ди. «И, – мин әйтәм, –Айдар абый, ул бит үзем өчен генә язылган шигырьләр!» «Шигырь – язганчы гына синеке ул, аннары халыкныкы», – дип җавап бирде Айдар абый.

Беренче китабым 40 яшемдә чыкты. Өченче китабым чыккач, Татарстан Язучылар берлегенә кабул иттеләр. Ләкин, дөресен әйткәндә, мин беркайчан да үземне профессиональ шагыйрь, язучы дип санамадым. Хәзер дә санамыйм. Әдәбиятка булган мәхәббәтнең чагылышыдыр ул миндә.



Каләмдәшләре Айдар Хәлим, Асия Юнусова белән

**– Сез – сәхнә кешесе, күп кичләрегез эштә узгандыр. Гаиләгезгә зыян китермәдеме бу?**

– Башка берәүгә кияүгә чыккан булсам, бәлки китергән дә булыр иде. Ләкин без бит ирем белән сәхнәдә танышкан кешеләр. Якуб Чаллы халык театрында режиссер ярдәмчесе булып эшли иде. Сәхнәдә бергә уйнаган да булды. Аннары өйләнештек. Балага яшь ярым чагында Якубны армиягә алдылар. Мин хатларны аңа гел шигырь белән яза идем. Якуб ул шигырьләрне блокнотына күчереп алып кайткан. Хәзер алар барысы да диярлек җырга әйләнделәр инде.

Армиядән кайткач, икебез дә культурада эшли алмабыз, дип уйлаштык та, ул заводка урнашты. Гастрольләрдән, туйлардан кайвакытта иртән генә кайтып керергә туры килсә дә, ирем караңгы чырай катмады миңа. Мин – һавадарак оча торган кеше инде, ул – салмаграк. Мин таратканны-чәчкәнне җыеп, мине тәртипләп яши Якуб. Аллага шөкер, малай белән кыз үстердек. Ике оныгыбыз бар. Улыбыз Наил әтисенә охшаган, һөнәре дә заводныкы, инженер-проектчы, кызыбыз мәдәният тармагында – КАМАЗда, ПРЗ заводында режиссер. Ул да эшен бик яратып эшли. Ә яраткан эшеңдә эшләү – ул ярты бәхет инде. Кызыбыз Нәфисә белән без коллегалар да, дуслар да – сөйләшеп сүз бетми. Балалар да татарча сөйләшеп үсте, оныкларыбыз Алия белән Салават та... Аллага шөкер. Алия театр мәктәбенең татар бүлегенә йөри.

Үзебезнең бала үстергән чакларны искә алам да мин, яшьлек белән генә түзелгәндер, дим. Балалар бакчасын шәһәрнең икенче башыннан бирәләр иде бит нишләптер. Чаналар күтәреп автобуска керәсең. Басып торырга да урын юк. Баланы кулдан кулга биреп кем алдынадыр утыртасың. Төшкәндә: «Бирегез әле минем баланы», – дип, кире сорап аласың. Балалар бакчага йөргәндә мин бакча хезмәткәре булып бетә яздым. Алар мәктәптә укыганда – мәктәп кешесе. Бөтен эшләрем бетергәч, ярты төнгә кадәр сценарийлар язып утыра идем. Әмма... барыбер дә балаларның миңа үпкәләр чуты бар дип уйлыйм. Алар белән бик шөгыльләнә алмадым бит. Чөнки яшәргә кирәк иде. Балалар бик мөстәкыйль булып үстеләр инде. Күршеләребез дә әйбәт булды, алар да ярдәм итте.
Миңа гел ике эштә эшләргә туры килде. Администрациядә эш сәгате биштә бетә, җидедә минем инде театр мәктәбендә дәресләрем башлана. Тугызда гына өйгә кайтып керәм. Әйт-кәнемчә, гастрольләрдән иртән генә кайткан чаклар да була. Битеңне тиз-тиз юасың, балаларыңны урнаштырасың да эшкә китеп барасың. Йокламыйча да.

**– Күпме энергия кирәк бит!**

– Әйе, Аллаһ миңа көч-дәрман биргән инде. Безнең әни мәрхүмә шундый иде. Ә әти йорт мәшәкатьләренә исе китми торган тынычрак кеше иде. Уттай печән өстендә, башын кыңгыр салып, скрипкада уйнап утырырга мөмкин иде ул.

**– Скрипкада уйный белә идемени әтиегез?**

– Скрипкада, гармунда, мандолинода... Үзлегеннән өйрәнгән. Мәктәптә укытудан туктагач, гарәп теле өйрәнде, калган гомерен мулла булып үткәрде. Туксан яшендә үлде. Соңгы елларын бездә, Чаллыда яшәде.

Олы яшендә тамырыннан кубарып алып килгәч, мин аңа күңелсез булмасын дип бик тырыштым инде. Бөтен мәчет картларын җыеп аш үткәрдем, әтине алар белән таныштырасым килде. Аннары үзе дә җәяүләп 48 нче комплекстагы мәчеткә йөри башлады.

**– Шәһәр картына әйләнде алайса?**

– Әйе. Минем белән бөтен мәдәни чараларга йөрде. Бөтен нәрсәдән хәбәрдар, «Картиналар галереясендә күргәзмә ачылган икән, нигә мине алып бармадың?» – дип, үпкә дә белдерергә мөмкин иде.

Әти монда чагында без бөтен гаиләбез белән анынча яшәдек. Мин генә түгел, ир дә, балалар да. Ул – тыныч кына үзенекен эшләтә торган кеше иде.

Сәламәтлеккә файдалы дип, кич белән кефир эчеп ята торган гадәте бар иде аның. Бервакыт шулай концерттан кайтып кердем. Кефир алырга онытылган. «Өйдә кефир юк», – ди әткәй. «И, онытканмын шул әткәй», – дим. «24 сәгать эшли торган кибетләр дә бар инде ул Чаллыда», – ди бу. Барып ал да дими, барма да дими. Кире чыгып киттем инде.

**– Зөләйха апа, сез руль артына бик соң утырдыгыз бугай?**

– Алтмыш яшемдә. Алтмыш яшемдә җир алып, йорт төзи башладык, алтмыш яшемдә машинага утырдым. Чөнки машинасыз эш бармаганын аңладым. Әҗмәкәйгә (Тукай районы Әҗмәкәй авылы) бишәр капчык цемент та алып кайта иде ул бәләкәй машинам. Ирем эштә. Урысларда «Необходимость обостряет разум» дигән сүз бар бит – дөрес ул. «Ничек курыкмыйча машина йөртәсең?» – диләр миңа. Курыкмаска, мин бит җүләр түгел. Куркам, тик барыбер йөртәм. Инде менә ун ел.

**– Өй салу да соңга калынган...**

– Пенсиягә чыгып, пенсия дә, хезмәт хакы да ала башлагач кына өйгә тотындык.

**– Пенсия акчасына өй салдым дигән кебек булды инде бу.**

– Алай ук түгел. Мин бит 7700 сум белән пенсиягә чыктым. Ә йорт төзи башлавыбыз кызык кына килеп чыкты безнең. Бервакыт җырчы Габидулла Хөрмәтуллиннарга кунакка бардык. Мин әйтәм: «Эх, үз йортыңның баскычында, этәч тавышлары тыңлап, китап укып утыр икән», – дим. «Менә монда буш җирләр бар бит, – ди Габидулла. – Алыгыз да төзегез».

450 мең сум кредит алып, җир сатып алдык. Дүрт башына дүрт казык кагып куйдык та беренче эш итеп шашлык пешердек. Мәрхүм Шәфәгать Салихов бар иде, Илдус Низамов, Габидулла... Бергә җырлашып утырдык. Күршеләр әйтә икән: «Болар казык каккач шулай шаулаша, авылда тора башласалар, нишләрбез», – диләр икән.

Өйне проектыннан башлап үзем уйлаганча төзедек. Менә быел инде, Аллага шөкер, икенче кышны чыгабыз. Өч бүлмәле фатир кадәр генә безнең өебез. Шунда дуслар, туганнар – бөтенебез сыя. Оныклар, балалар килә, атна саен мунча ягыла.

Без бит авыл кешеләре. Авылныкы булмыйм дисәң, яңадан туып яңадан яшисе. Менә, Алла боерса, җитмештән соң эштән дә туктасам әле... Без яшь чакта безнең яшьтәге әбиләр җәй көне киез ката киеп капка төбендә утыралар иде инде.

**– Авылда мал асрамыйсызмы?**

– Кая ул! Минем бит сумка гел җыйналган. Әйдә, дисәләр, тотам да чыгып китәм. Шуңа күрә бакчамда да чәчәк кенә үстерәм. Ике ел рәттән Абхазиядә сабантуй үткәрдем. Аңа кадәр Кырымда.

**– Зөләйха апа, сездән ниндидер сер дә ишетәсе килә инде минем. Беркайчан беркемгә әйтмәгән серегез белән бүлешегез әле.**

– Миндә нинди сер булсын? Юк, серлерәк булсаң, әйбәттер ул, әлбәттә. Ләкин минем иремнән дә яшерен серем булмады. Чөнки әйтми түзә алмыйм мин аны. Бервакыт шулай Якубка нәрсәгәдер ачуым килде. Мин әйтәм: «Все, сөйләшмим әле мин моның белән берәр атна», – дим. «Ну ярар, һич югы бер өч көн», – дим. Шул ук көнне ялгыш эндәштем дә сөйләшмәскә уйлаганым исемә төште. Ә ни өчен сөйләшмәскә уйлаганым онытылган иде инде.

**– Гаиләдә кайсыгыз баш булып яшәде, Зөләйха апа?**

– Якуб, билгеле. Ә мин дәшми-тынмый гына үземчә эшләүче. Аннары иремә әйтәм: «Кара әле, Якуб, – дим, – теге вакытта син шулай әйткән идең бит, менә шулай эшләп тә куйдык. Ничек әйбәт булды. Дөрес әйткән булгансың бит син», – дим.

Кибетләрдә әйбер юк вакыт. Киемгә кадәр үзем тегә идем. Пенсияләрне, эш хакларын түләмиләр. Кыз мәктәптә укый әле ул чакта, автобус белән барасы, автобуска түләр өчен биш тиен юк. Представляешь?

**– Представляю. Мин дә ул заманда яшәдем бит.**

– Менә шуңа гарьләнеп туйлар алып бара башладым инде. Һәм пенсиягә чыгуга – шалт туктадым. Ничек булды ул. Бервакыт туй алып барырга чакырдылар мине. Туйда әти кеше сүз алып сөйли башлады. «Бүген улы- бызның туен алып баручының кем икәнен беләсезме?» – ди. Мин уйлыйм инде: «Атказанган мәдәният хезмәткәре, фәлән-төгән дип әйтер» – дип. Ә ул беләсеңме нәрсә диде. «Әниләре белән без өйләнешкәндә, Зөләйха ханым безнең туйны да алып барган иде», – диде. Һәм мин шунда үземне мамонт итеп хис иттем.

**– Зөләйха апа, нәкъ менә сездән, атказанган мәдәният хезмәткәреннән, бүгенге эстрадага карашыгызны сорамасам, дөрес булмас кебек.**

– Бүген техник мөмкинлекләр күп инде. Бик шәп концертлар карарга туры килә. Шоу дип исең китеп кайтасың. Әмма... соңыннан искә төшерә башлыйсың – шунда яңгыраган җырларның берсе дә истә калмаган була.

Аннары берәрсе көй яздым дип тыңлатып карый. Тик ул көйне кайдадыр ишеткән кебек инде. Кемдер төрек җырын ала да, аз гына үзгәртеп, татар җыры ясый. Кемдер – итальян җырын...

Ә шулай да, беләсеңме, мин вакытка ышанам. Иләчәккә барыбер вакыт иләгеннән иләнгән яхшы җырлар гына калачак. Менә бездә хәзер үк элеккеге җырларга кайту тенденциясе бара бит. Поруляр җырчыларның репертуарына игътибар итегез: һәрберсендә диярлек безнең яшьлектәге матур җырлар бар.

**– Ә талантсызларның сәхнәгә күтәрелүенә ничек карыйсыз?**

– Күтәрелсеннәр. Сәхнә кешесе өчен иң мөһиме талант түгел, тырышлык бит. Була шундый талантлар – морҗа белән ишек арасыннан үтә алмыйлар. Аларның талантыннан ни файда? Кайберәүләргә карап торасың, таланты зур түгел инде дип уйлыйсың. Әмма тырышлык, үҗәтлек белән алар бик зур заллар җыя. Сәхнә кешесенә үҗәтлек кирәк. Уңышсызлыктан сабак алып, җиде кат ябылган ишекне сигезенче кат шаку кирәк.



“Эврика” шәһәр мәдәният үзәгендә сәхнәдәшләре һәм !Шәһри Чаллы”, “Көмеш кыңгырау” газеталары хезмәткәрләре белән

Мин үзем сәхнәне изге урынга саныйм. Кайчакта: «Сәхнәгә чыгып берәр сүз әйтегез әле», – диләр. Мин менәргә кыймый торам. Чөнки алмаш аяк киемем булмый. Кышкы аяк киеме белән ничек сәхнәгә күтәреләсең?

**– Зөләйха апа, «Тормышыгыздан канәгатьме?» – дип сорарга тиеш инде мин бүген сездән.**

– Канәгать. Гомер буе яраткан эшемдә эшләдем. Яраткан кешеләрем белән аралашып яшәдем. Зур исемнәр ала алмаганмындыр, әмма...

**– Сез болай да исемле бит инде – Зөләйха Минһаҗева!**

– Әйе-е-е. Бервакыт шулай, бер җитәкче эшемне, шәхсән үземне кимсетебрәк сөйләнә башлаган иде. «Туктагыз әле, – дидем мин аңа. – Мин бит инде (!) Зөләйха Минһаҗева. И вы с этим ничего не поделаете, урыс әйтмешли!

Менә шулай тәмамланды Зөләйха апа белән әңгәмәбез. Хәер, юк – саубуллашканда бер шәп дүрт юллыгын сөйләгән икән әле ул:

*Һәр бәхетле мизгел өчен*
*Нидер түләргә кирәк.*
*Оҗмахка керү өчен дә,*
*һич югында, ким дигәндә,*
*Башта үләргә кирәк...*